РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 664** **2015 елның 17 марты**

# Янгын һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендәге торак йортлар һәм башка объектлар янында оператив хезмәтләрнең тоткарлыксыз керүен, янгын сүндерү җайланмасын һәм махсус техника урнаштыруны тәэмин итү турында

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 маендагы 390 номерлы карары нигезендә, шулай ук янгын һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, шәһәр халкының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, янгыннарда кешеләрнең үлемен һәм җәрәхәтләнүен булдырмау, шулай ук оператив хезмәтләрнең (янгын сагы хезмәте, эзләү-коткару хезмәте, полиция, ашыгыч медицина ярдәме хезмәте, газ һәм электр челтәрләренең авария хезмәте) тоткарлыксыз керүен, янгын сүндерү җайланмасын һәм махсус техника урнаштыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Президентының «Ашыгыч оператив хезмәтләр транспорт чараларының биналарга һәм корылмаларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итү турында» 2014 елның 18 декабрендәге 714 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, **карар бирәм:**

1. «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» МУПка (Харитонов А.В.) идарәче компанияләр, торак-төзелеш оешмалары, торак милекчеләре ширкәтләре һәм милек формасына бәйсез рәвештә башка оешмалар җитәкчеләре белән берлектә:

1.1. Янгын һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, йорт яны территориясендә оператив хезмәтләрнең янгын сүндерү техникасын һәм махсус техникасын урнаштыру өчен тоткарлыксыз керүен һәм якын килүен тәэмин итәргә.

1.2. Янгын һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, оператив хезмәтләрнең тоткарлыксыз керүенә, янгын сүндерү һәм махсус техника урнаштыруга комачаулый торган коймалар урнаштыруга юл куймаска.

1.3. Юлларны, торак биналарга, тышкы янгын баскычларына һәм янгын сүндерү максатларында файдаланыла торган су чыганакларына керү һәм якын килү юлларын төзек хәлдә тотарга, кышын кардан чистартырга.

1.4. Янгын сүндерү бүлекчәләренә оператив хезмәтләрнең янгын сүндерү һәм махсус техникасы керүгә комачаулый торган ремонт-торгызу эшләрен үткәрү турында вакытында хәбәр итәргә.

1.5. Ремонт-торгызу эшләрен алып бару урыннарын әйләнеп узу юнәлеше күрсәткечләрен урнаштыруны оештырырга.

1.6. Чыгу капкаларын һәм чыгу юлларын капламаска.

1.7. Янгын урынына керү юлы киңлеген ким дигәндә 6 метр тәэмин итәргә.

1.8. Тыкрыкларны, янгын сүндерү техникасы борылсын өчен, 15 х 15 метрдан да ким булмаган зурлыктагы буш мәйданчыклар белән тәэмин итәргә; янгын гидрантлары кое капкачларына автомобильләр тукталышын тыярга.

1.9. Елның теләсә кайсы вакытында янгынга каршы су чыганакларына янгын сүндерү техникасы керүен һәм якын килүен тәэмин итәргә.

1.10. Ишегалды территорияләрендә янгын сүндерү техникасы керүен һәм урнаштыруны чикләүче каршылыклар (шлагбаумнар, киртәләр) урнаштыруны булдырмаска.

1.11. Янгын сүндерү һәм махсус техника кую өчен билгеләнгән мәйданчыкларны автомобильләр кую урыннарын тыя торган һәм тәүлекнең теләсә кайсы вакытында күренә торган билгеләр белән билгеләргә.

1.12. Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә, биналар һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары тирә-юнендә үсүче, күтәрү механизмнарын урнаштыруга һәм кешеләрне һәм мөлкәтне коткару, янгын сүндерү һәм авария-коткару эшләре үткәрү өчен оператив хезмәтләрнең янгын сүндерү һәм махсус техникасын тоткарлыксыз керүенә комачаулаучы яшел утыртмаларны казып алуны оештырырга һәм башкарырга кирәк булган биналар исемлеген билгеләргә.

1.13. Һәр күпфатирлы торак йортның йорт яны территориясендә, территориядә булган янгын сүндерү техникасы үзенчәлеген исәпкә алып, ашыгыч оператив хезмәтләрнең транспорт чараларын кую өчен, мәйданчык билгеләргә.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсенә (Садыйков А.А.), ЮХИДИ бүлегенә (Крайнов А.Г.) тәкъдим итәргә:

2.1. Массакүләм мәдәни чаралар уздырганда, кешеләр күпләп була торган территориядә яки объектларда оператив хезмәтләрнең янгын сүндерү һәм махсус техникасы хәрәкәтенә комачаулый торган күпләп автотранспорт тупланган урыннарны ачыкларга һәм аны эвакуацияләү чараларын күрергә.

2.2. Үзара хезмәттәшлек кысаларында, «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 16 нчы отряды» ФДКУга (Кашихин Е.В.), Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Түбән Кама муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы хезмәтенә (Шиһапов К.Ф.) янгын сүндерү техникасы керү юлларына һәм якын килү урыннарында парковкаланган автотранспорт чаралары хуҗаларын билгеләү буенча кирәкле ярдәм күрсәтергә. Янгын сүндерү техникасы керү һәм якын килү юллары, шулай ук аларны урнаштыру урыннары ябылган очракта, оператив хезмәтләрнең янгын сүндерү һәм махсус техникасының керү, якын килү һәм урнаштыру урыннарыннан комачаулаучы транспорт чараларын тиз эвакуацияләүне оештырырга.

3. «Федераль янгынга каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 16 нчы отряды» ФДКУга (Кашихин Е.В.), Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Түбән Кама муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы хезмәтенә (Шиһапов К.Ф.) тәкъдим итәргә:

3.1. Булган биналарны, корылмаларны, шулай ук янгын сүндерү техникасына тоткарлыксыз керү тәэмин ителмәгән биналарны һәм корылмаларны исәпкә алырга.

3.2. Янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килми торган тыкрыклар (борылыш мәйданчыкларысыз) булган йорт яны территорияләрен исәпкә алырга.

3.3. Йорт яны территорияләренә янгын техникасының тоткарлыксыз керүенә һәм янгын сүндерү техникасын урнаштыру мөмкинлегенә күпфатирлы торак йортларның йорт яны территорияләренең гамәлдәге торышын тикшерергә.

3.4. Җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән эшләү бүлеге (Камелина М.В.) белән берлектә янгын чыккан очракта янгын сүндерү һәм махсус техниканың тоткарлыксыз керүен тәэмин итү зарурлыгы турында халыкка аңлату эшләрен үткәрүне оештырырга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары, агитация - пропаганда чаралары аша, махсус әдәбият бастыру һәм тарату, башка формалар һәм ысуллар белән янгын сүндерү техникасының янгын урынына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле чаралар турында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А. Хәмидуллинга йөкләргә.

Т.Х. Камалетдинов